**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул.Школьная, д.5, с.Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Мәктәп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс (84396) 4-22-23 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

№121 18.12.2023 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең 2012 елның 15 маендагы № 42 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2023 елның 13 июнендәге № 258-ФЗ, 2023 елның 10 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» № 286-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен түләтүләр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турында таләпләр һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең 2012 елның 15 маендагы №42 карарына (Советның 2021 елның 22 ноябрендәге №51, 2023 елның 27 июнендәге № 100 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктчасының 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «үз карамагындагы муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;».

1.2. 2.5 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәтенең кадрлар бүлеге үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Р.Гатина